
# Сыйфатларны гомумиләштерел кабатлау

# сыйфат



предметның билгесен
дәрәҗә
нинди ? кайсы? кайдагы?
сыйфатланмыш
исемне ачыклый
аергыч,
хәбәр була

- **Төркемнәрдә эш**
- 1 төркем. Сыйфат дәрәҗәләре нәрсәне белдерә? Нинди дәрәҗәләр була? Мисаллар.
- 2 төркем. Ясалышы буенча сыйфатларның нинди төрләре бар? Нинди сыйфат ясагыч кушымчаларны беләсез? Мисаллар.
- 3 төркем. Сыйфатларның исемләшүен аңлатырга. Мисаллар китерергә.

# Сыйфат дәрәҗәләре

1. **Гади дәрәҗә-** *предметның гадәти билгесен белдерә.*

**2. Чагыштыру дәрәҗәсе-**

*гади дәрәҗәдәге сыйфатка –рак, -рәк кушымчасы ялганып ясала.*

**3. Артыклык дәрәҗәсе** *–бер предметтагы билгенең икенче бер предметтагы шундый ук билгедән артык икәнлеген белдерә . Өч төрле юл белән ясала:*

*а) ап-ак, кып-кызыл, ямь-яшел;*

*ә) иң, җете, дөм, үтә көчәйткеч кисәкчәләр;*

*в) бер үк сыйфатны кабатлау аша.*

## 4. Кимлек дәрәҗәсе-

*предметтагы билгенең гади дәрәҗәдән кимрәк булуын белдерә,-су, -ча, -сыл, -сел, -мса, -гылт, -гелт,- елҗем кушымчалары ярдәмендә ясала.*

# Сыйфат дәрәҗәләре

**1. Гади дәрәҗә-** *предметның гадәти билгесен белдерә.*

**2. Чагыштыру дәрәҗәсе-** *гади дәрәҗәдәге сыйфатка –рак, -рәк кушымчасы ялганып ясала.*

**3. Артыклык дәрәҗәсе** *–бер предметтагы билгенең икенче бер предметтагы шундый ук билгедән артык икәнлеген белдерә . Өч төрле юл белән ясала:*

*а) ап-ак, кып-кызыл, ямь-яшел;*

*ә) иң, җете, дөм, үтә көчәйткеч кисәкчәләр;*

*в) бер үк сыйфатны кабатлау аша*

**4. Кимлек дәрәҗәсе-** *предметтагы билгенең гади дәрәҗәдән кимрәк булуын белдерә,-су, -ча, -сыл, -сел, -мса, -гылт, -гелт,- елҗем кушымчалары ярдәмендә ясала.*

# Сыйфатларның ясалышы:

1. *тамыр*
2. *ясалма*
3. *кушма*
4. *парлы*
5. *тезмә*

# Сыйфатларның **исемләшүе.**

- Сыйфат сыйфатланмыштан башка да кулланылырга мөмкин. Бу күренеш сыйфатларның **исемләшүе** дип атала.

***Кадерлеләремә*** (әти-әниемә) КҮЧТӘНӘЧ алып кайттым.

# **Исемләшкән** сыйфатлар.

- Исемләшкән сыйфатлар, исемнәр кебек үк, **килеш** , **сан, тартым** белән төрләнә.

Җөмләнең **теләсә кайсы** кисәге булып килә.

# Тест биремнәре

| | |
|---|---|
| 1. Сыйфат нинди сүз төркеме ? | ***а) мөстәкыйль сүз төркеме*** |
| | ***ә) модаль сүз төркеме*** |
| | ***б) бәйләгеч сүз төркеме*** |

| | |
|---|---|
| **2. Сыйфат нәрсәне белдерә?** | ***а) предметның санын*** |
| | ***ә) предмет билгесен*** |
| | ***б) эш-хәлнең билгесен*** |

| | |
|---|---|
| **3. Сыйфатларны табыгыз** | *а)ялкау, эшчән* |
| | *ә) тырыш, баручы* |
| | *б) эшләгән, сүзчән* |

| | |
|---|---|
| 4. Ясалышлары буенча болар нинди сыйфатлар?<br>тәмле, уйчан, әдәпсез | *а) тамыр* |
| | *ә) ясалма* |
| | *б) тезмә* |

| | |
|---|---|
| 5. Сыйфат ачыклап килгән сүз ничек атала? | *а) саналмыш* |
| | *ә) аерылмыш* |
| | *б) сыйфатланмыш* |

| | |
|---|---|
| **6. Сыйфатларның дәрәҗәсен билгелә . кызгылт, күксел, салкынча, алсу** | *а) артыклык* |
| | *ә) чагыштыру* |
| | *б) кимлек* |

| | |
|---|---|
| **7. Сыйфатлар нинди җөмлә кисәге булып килгән?**<br>***Зур йорт, түгәрәк өстәл, уйчан бала, кызыл алма*** | *а) тәмамлык* |
| | *ә) аергыч* |
| | *б) хәл* |

8. Бу нинди сыйфатлар?

*Матур-ямьсез, зур-кечкенә, эшчән-ялкау, батыр-куркак*

*а) омоним*

*ә) синоним*

*б) антоним*

| | |
|---|---|
| 9. Кайсы сыйфат дәрәҗәсе 3 төрле юл белән ясала? | *а) гади* |
| | *ә) чагыштыру* |
| | *б) артыклык* |

| | |
|---|---|
| **10. Бу нинди сыйфатлар?** ***Матур, чибәр, сылу, гүзәл. Ярлы, хәерче, фәкыйрь. Батыр, герой, каһарман, баһадир. Яхшы, әйбәт, ару, шәп.*** | *а) синоним* |
| | *ә) антоним* |
| | *б) омоним* |

# Тестның дөреслеген тикшереп үтик:

1– а

2– ә

3– а

4– ә

5– б

6– б

7– ә

8– б

9– б

10– а

## Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы.

Яңгырдан соң урманда матур гөмбәләр үсеп чыга. Гөмбә ит кебек үк туклыклы. Тик агулыларын гына таный белергә кирәк.Майлылары тәмлерәк тоела.

## Антонимын язарга:

озын -,парлы -, иске - ,акыллы - , аяз -, начар - ,арзан - , биек -, кечкенә-, авыр - ,тырыш - ямьсез - ,бай-.

## Синонимын табарга:

шук - , пычрак - , әдәпле - , шатлыклы - , тәкәббер - , вак - , җайлы -,чибәр - , олы - .

# Сыйфатларга анализ ясагыз

***Күктә алсу кояш көлә. Әминәнең кызгылт күлмәге бар. Белемледән үрнәк ал. Юлда яланаяклы бала күренде.***

| сыйф. | сыйфатланмышы | ясалышы | дәрәҗәсе | исемләшкәндә | | | җөмләдәге вазифасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | сан | тартым | килеш | |
| | | | | | | | |

# Рәсемгә карата сыйфатлар уйлап языгыз



# Өй эше

.....күк итәгенә барып тоташкан, очы -кыры күренмәгән бер.... урман бар. Ул урманда .... агачлар гөрләп үсәләр, .... җиләкләр кызарып пешәләр. Анда ... бүреләр, ....төлкеләр , ....куяннар, ....еланнар яшиләр.